ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**БОЕРЫК**

13.08.2020 № 160-од

Казан шәһәре

Чараларның элек чыгарылган боерыкларда билгеләнгән аерым этапларын үткәрү турында

Боерык бирәм:

1. Чараларның Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының элек чыгарылган боерыкларында билгеләнгән түбәндәге аерым этапларын үткәрергә:

- «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасында «Эхо веков в истории семьи - Тарихта без эзлебез» шәҗәрә бәйрәме турында» 2019 елның 21 октябрендәге 190-од номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында «Эхо веков в истории семьи - Тарихта без эзлебез» ел саен үткәрелә торган шәҗәрә бәйрәмен уздыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының 2020 елның 27 гыйнварындагы 16-од номерлы боерыгы белән гамәлгә куелган Татарстан Республикасында «Эхо веков в истории семьи - Тарихта без эзлебез» ел саен үткәрелә торган шәҗәрә бәйрәменең зона этабын 2020 елның 15 сентябреннән алып 25 сентябренә кадәр, республика этабын 2020 елның 29 октябреннән алып 29 ноябренә кадәр үткәрергә. Республика этабының йомгакларын чыгару;

- Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының «Минем шәҗәрәм» республика генеаологик тикшеренүләр конкурсы турында» 2020 елның 27 гыйнварындагы 17-од номерлы боерыгы белән гамәлгә куелган «Минем шәҗәрәм» республика генеаологик тикшеренүләр конкурсының республика этабын 2020 елның 4 сентябреннән алып 10 сентябренә кадәр;

- Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының «2020 елда Татарстан Республикасы муниципаль архивларының грант ярдәме алуга конкурсы турында» 2020 елның 28 гыйнварындагы 20-од номерлы боерыгы белән гамәлгә куелган конкурс проектларын Грантка дәгъва

кылучылар тарафыннан гавами яклау этабын 2020 елнын 16 сентябреннән алып 22 сентябренә кадәр.

2. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының «Чараларның аерым этапларын үткәрүнең элек чыгарылган боерыкларда билгеләнгән срокларын күчерү турында» 2020 елның 29 апрелендәге 85-од номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам

Рәис Г.З. Габдрахманова